**ГЛАВА**
**БОЛЬШЕКАБАНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОНЫ**
**ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ**
**БАШЛЫГЫ**
Кәньяк урамы, 1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2023елның «06» июле** **5 номер**

## КАРАР

### Шәхси торак төзелеше объектын төзүнең рөхсәт ителгән чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 нчы маддәсе, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Олы Кабан авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 нче маддәсе нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне, гражданнарның һәм аларның берләшмәләренең мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Руссков Алексей Николаевичның гаризасы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. Кадастр номеры 16:24:160101:1686 булган, гомуми мәйданы 400 кв. м булган, ТР, Лаеш районы, Олы Кабан авылы адресы буенча урнашкан җир кишәрлегендә рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясе 2023 елның 28 июлендә 15.00 сәгатьтә ТР, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авылы, Җиңү урамы, 5 йорт адресы буенча Олы Кабан мәдәният йорты бинасында ачык тыңлаулар уздырырга кирәк.
3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне 2023 елның 27 июленә кадәр Татарстан Республикасы Лаеш районы Кече Кабан авылы, Көньяк урамы, 1 йорт адресы буенча яки (8843 78) 4-22-02 телефоны буенча язма рәвештә җибәрергә.
4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Олы Кабан авыл җирлеге башлыгы** **Р.Ш. Илһамов**